| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Старосляковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Иске Эсләк авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.04.2026 Иске Эсләк авылы № 9-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25 номерлы Федераль законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Президентының 31.12.2025 елның 1009 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Советының кайбер карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

1.1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру тәртибен раслау турында һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 27-1 номерлы карары;

1.2. «Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр тапшыру турында һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Советы карары 2021 елның 16 августының 14-2 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Әхмәтова